РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
МЭР ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ МЭРЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2023 елның 7 ноябре** **№ 11**

«Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында» Кукмара шәһәре Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 һәм 31 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына, Кукмара шәһәре Советының 2020 елның 17 февралендәге 5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә таянып карар бирәм:

1. «Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында» Кукмара шәһәре Советы карарының кушымта итеп бирелә торган проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.
2. «Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында» карар проектын әзерләү буенча комиссия тарафыннан 2023 елның 17 ноябреннән 4 декабренә кадәр экспозиция һәм җыен үткәрү юлы белән гавами тыңлаулар уздырырга.

3. Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрүне 4 декабрьгә 17.00 сәгатькә Кукмара шәһәре, Ленин урамы, 38 йорт адресында урнашкан Район мәдәният йорты бинасына билгеләргә.

4. «Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында» карар проекты һәм аңа карата мәгълүмат материаллары экспозициясен 2023 елның 17 ноябреннән 4 декабренә кадәр Татарстан Республикасы, Кукмара районы,

Кукмара шәһәре, Ленин ур., 15 йорт адресындагы Кукмара шәһәре Башкарма комитеты бинасында үткәрергә;

5. Экспозициягә килүчеләргә экспозиция урнаштыру урынында түбәндәге график буенча консультация үткәрергә: сишәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә 9.00 сәгатьтән 12.00 гә, 13.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорда.

6. Билгеләргә:

- «ТКукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында» карар проекты Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында http://kukmor.tatarstan.ru// веб-адрес буенча 2023 елның 8 ноябреннән дә соңга калмыйча урнаштырыла;
- карарның 1 пунктында күрсәтелгән карар проекты буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гавами тыңлауларда катнашучылар 2023 елның 4 декабренә кадәр (әлеге датаны да кертеп) Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Кукмара шәһәре, Ленин урамы, 15 йорт адресына «Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында» карар проектын әзерләү Комиссиясенә язмача, шулай ук гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышы барышында язмача һәм телдән кертә алалар.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Кукмара шәһәре Мэры урынбасары — А.Р. Аксанова

Кушымта
проект

Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре турында

Территориянең тотрыклы үсеше өчен шартлар тудыру, шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен җайга салу, Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә тәртипле һәм нәтиҗәле итеп җирдән файдалануны һәм төзелешне тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 31 статьясы нигезендә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

1. Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресында бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Кукмара шәһәре Мэры С.Д. Димитриев